КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь г.Казань № 1110

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 681 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар билгеләнгән критерийләр буенча күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатлы булулары турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар билгеләнгән критерийләр буенча күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатлы булулары турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 ел, 22 август, 681 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 12 июнь, 482 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар билгеләнгән критерийләр буенча күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатлы булулары турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта «Бәяләмә бирү (бәяләмә бирүдән баш тарту) кагыйдәләре белән билгеләнгән срок тәмамланганчы 10 көннән дә соңга калмыйча аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Бәяләмә йә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан имзалана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин